КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 гыйнвар г.Казань № 5

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1194 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 16 сентябрь, 793 нче; 2025 ел, 2 август, 559 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VII бүлектә:

7.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау турында декларациядә, җитештерү экология контролен оештыру һәм аның нәтиҗәләре турында хисапта, Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны исәпкә алу буенча программа-техник тәэмин итү системасында белешмәләр актуальләштерелмәгәндә төп производстволарның технологик процесслары тасвирнамәләре, әйләнә-тирә мохитне пычрату чыганаклары үзгәрү, пычраткыч матдәләрне чыгаруларны, агызуларны зарарсызландыру буенча техник чаралар тасвирнамәләре, җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану, зарарсызландыру һәм урнаштыру технологияләре үзгәрү турында хисапта, шулай ук шул ук чор өчен әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объект категориясе үзгәрү турында мәгълүматта чагылдырылган атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгарулар, пычраткыч матдәләрне су объектына

агызулар, барлыкка килгән һәм урнаштырылган калдыклар массасы күләмнәре узган чор өчен 10 проценттан артыграк үзгәрү.»;

түбәндәге эчтәлекле 7.9 – 7.13 пунктлар өстәргә:

«7.9. Контрольдә тотылучы зат Министрлыкка узган календарь елда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында аның икътисадый эшчәнлек төрләренә туры килми торган калдыклар барлыкка килү турында белешмә бирү.

7.10. Автотранспорт чараларын ремонтлау эшчәнлеген гамәлгә ашырган контрольдә тотылучы затның узган календарь елда эшкәртелгән май калдыклары, эшкәртелгән фильтрлар, майлы чүпрәкләр, автомобиль шиннары барлыкка килү турында белешмәләре булмау.

7.11. Автотранспорт чараларын юу хезмәтләре күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашырган контрольдә тотылучы затның узган календарь елда агып төшә торган суларны механик чистарту калдыклары (утырмалары), су өстенә чыккан нефть продуктлары барлыкка килү турында белешмәләре булмау.

7.12. Төзелеш буенча эшчәнлек гамәлгә ашыра торган контрольдә тотылу затның узган календарь елда төзелеш калдыклары (кирпечವаклары, бетон әйберләре ваклары һәм тимер-бетон әйберләре ваклары, биналарны җимерүдән калган чүп-чар, лаклы буяу материаллары калдыклары) барлыкка килү турында белешмәләре булмау.

7.13. Календарь ел дәвамында әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектның категориясе Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган объектларны исәпкә алу буенча программа-техник тәэмин итү системасында югарыдан түбәнрәк категориягә үзгәрү факты икәү һәм аннан күбрәк булу.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 940 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1368 нче; 2022 ел, 25 октябрь, 1137 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1226 нчы; 2024 ел, 7 май, 311 нче; 2024 ел, 2 сентябрь, 714 нче; 2025 ел, 2 август, 559 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан Министрлык адресына кергән мөрәҗәгатьләр буенча консультация бирү гамәлгә ашырыла (төбәк дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм үткәрү белән бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирелә). Консультация түләүсез бирелә.

Консультация Министрлыкның вазыйфаи заты тарафыннан телефон аша, видеоконференцэлемтә ярдәмендә, шәхси кабул итү вакытында яисә профилактик чара, контроль (күзәтчелек) чара үткәрү барышында бирелергә мөмкин.

Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан консультация, шул исәптән язма консультация бирү әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктына күрсәтелгән җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла. Телдән консультация биргәндә җавап йә шул ук вакытта, йә кергән сорауны карап тикшерү таләп ителгән очракта, гариза бирүченең күрсәтелгән телефоны буенча бирелә.

Консультация барышында үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) чара, Министрлык вазыйфаи затларының карарларын һәм гамәлләрен, контроль чаралар үткәрү нәтиҗәләрен бәяләүне үз эченә алган мәгълүмат бирелә алмый.

Министрлык тарафыннан консультацияләр исәбе алып барыла.

Бертөрле мөрәҗәгатьләр буенча консультация бирү Татарстан Республикасының баш дәүләт инспекторы тарафыннан кул куелган язма аңлатманы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

VII бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.7 – 7.9 пунктлар өстәргә:

«7.7. Узган календарь елда контрольдә тотылучы зат тарафыннан Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасы буенча гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеген раслау турында» 2006 елның 18 маендагы б-27/б-623 номерлы боерыгында исемлеге билгеләнгән гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару күләме, аңа кадәрге ел белән чагыштырганда, «Глонасс+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан алынган мәгълүмат буенча эшләр башкару дәвамлылыгы 10 проценттан күбрәк артканда, 30 проценттан күбрәк киму (акваториядә чыгару).

7.8. Контрольдә тотылучы зат тарафыннан һәркем карый ала торган урында, әлеге затның гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга лицензиясе булу турында белешмәләр булмаганда, сату факты ачыкланган датага карата Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасы буенча гомумтаралган файдалы казылмалар исемлеген раслау турында» 2006 елның 18 маендагы б-27/б-623 номерлы боерыгында исемлеге билгеләнгән гомумтаралган файдалы казылмалар Татарстан Республикасы территориясендә барлыкка килгән ваклап сатуның уртача статистика бәясеннән 15 һәм аннан күбрәк процентка түбәнрәк бәягә сату турында белдерү урнаштыру факты.

7.9. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү һәм гариза бирүче мәнфәгатьләрендә файдалану өчен су төбен тирәнәйтү эшләрен башкарганда алынган су төбендәге грунттан файдалану турында карар булмаганда һәм аны утильләштерүгә шартнамә төзү турында белешмә булмаганда су объектын су төбен тирәнәйтү эшләрен башкару өчен файдалануга тапшыру турында карар контрольдә тотылучы зат тарафыннан алынганнан соң 30 календарь көн узу.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин